## «Сәйяр» театр фестиваль бәйгесендә Балтач гимназиясе театр коллективы җиңүче булды

Татарстан Мәгариф һәм фән министрлыгы «Сәхнә», «Салават күпере» журналлары, «Кәрим Тинчурин исемендәге Татар дәүләт драма һәм комедия театры» белән берлектә республикакүләм «Сәйяр» театр фестиваль бәйгесенә старт бирде. Ул мәктәп, район, зона һәм республика турларын үз эченә алып, 2023нче елның апреленнән октябрь аена кадәр дәвам итә. Шушы көннәрдә фестивальнең муниципаль этабына нәтиҗә ясалды.

Фестиваль балаларда рухи мәдәният һәм татар халкының милли мирасына сак караш тәрбияләү максатыннан үткәрелә. Яшь буынның татар язучылары һәм драматурглары иҗатын өйрәнүгә мотивациясен арттыру, театр сәнгатенә укучыларның игътибарын җәлеп итү, балалар һәм яшьләргә сәнгать-эстетик һәм әхлакый тәрбия бирү, иҗади сәләтле укучыларны ачыклау һәм аларга ярдәм итү-фестивальнең төп бурычлары.

«Сәйяр» театр фестиваль бәйгесендә Балтач гимназиясе театр коллективы беренче урынны яулады. Җитәкчеләре: С.А.Егорова, А.И.Хәкимҗанова.

Котлыйбыз! Афәрин!

